ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**11.08.2020**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 1477**

2020 елның III кварталына Зеленодольск муниципаль районы буенча торак урынының 1 квадрат метр гомуми мәйданының уртача базар бәясе турында

Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «2020 елның икенче яртыеллыгына Россия Федерациясе буенча торак урынының бер квадрат метр гомуми мәйдан бәясе нормативы һәм 2020 елның III кварталына Россия Федерациясе субъектлары буенча торак урынының бер квадрат метр гомуми мәйданының уртача базар бәясе күрсәткечләре турында» 2020 елның 29 июнендәге 351/пр номерлы боерыгы нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2020 елның III кварталына Зеленодольск муниципаль районы буенча гомуми торак мәйданының 1 квадрат метрының (сумнарда) уртача базар бәясен, күрсәтелгән социаль түләүләр федераль бюджет акчалары исәбеннән торак урыннары сатып алуга (төзелешкә) бирелә торган барлык категория гражданнар өчен социаль түләүләр күләмен исәпләү өчен, 53 024 (илле өч мең егерме дүрт) сум күләмендә расларга.
2. Зеленодольск муниципаль районы Советының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О.А. Матвеевага йөкләргә.

Җитәкче М.П. Афанасьев